| | |
|---|---|
| СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2025 ел № 7

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге Советының Регламентына өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советының 20.12.2010 №12 карары белән расланган Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советы регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.Регламентның 35 статьясына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Карар кабул иткәндә хәлиткеч тавыш хокукына ия депутатларның "хуплыйм" һәм "каршы" бирелгән тавышлары саны тигез булган очракта, Совет утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була».

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә baltasi.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзекләндерү, төзелеш, хокукларны яклау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гильфанов